| СОВЕТ МАМАДЫШ-АКИЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** Мамадыш-Әкил **КАРАР**

**2024 елның "05" декабре** ав. **№187**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт хакы күләмен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында» 30.09.2020 №4 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Советның 23.09.2022 №90, 30.12.2022 №106, 10.06.2024 №171 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «28.03.2018 ел, № 182 карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәтенә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында» 30.09.2020 елның 4 номерлы карарына (Советның 23.09.2022 №90, 30.12.2022 №106, 10.06.2024 №171 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1). 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2) икенче абзацта «18 260 (унсигез мең ике йөз алтмыш) сум күләмендә һәм 19 569 (унтугыз мең биш йөз алтмыш тугыз) сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү» сүзләрен «19 173 (унтугыз мең йөз җитмеш өч) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 20 548 (егерме мең биш йөз кырык сигез) сум күләмендә» сүзләре белән алмаштырырга;
2). 2 пунктта:
2.1) беренче абзацта «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан»сүзләренә алмаштырырга;
2.2) икенче абзацта «18 260 (унсигез мең ике йөз алтмыш) сум күләмендә» сүзләрен «19 173 (унтугыз мең йөз җитмеш өч) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга»;
3) 3 пунктта «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга.;
4) "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Кушымта
Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советының 2024 елның 05 декабрьндәге № 187 карарына

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КУЛЭМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфаларының атамалары** | **Айлык күләме вазифа хезмәт хакы, сум** |
|---|---|
| Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) | 18 607 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин урамы, 50 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Татар Танае авылы, Үзәк урам, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы), Паново авылы, Үзәк урам, 26в йорт (авыл клубы бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Мамадыш-Әкил авыл Җирлек башлыгы,
Совет рәисе: Ф.Ф.Мирхәтуллин